## 7. Салават күпере

Бер адым калмый артымнан йөгерә бала чагым:
Салават күпере төшкән, кил, барып карыйк тагын

Кушымта: Уйларым малай чак булып, сызганып балакларын,
Йөгерә юеш чирәмнән, төсләрнең сайлый алын

Җил килеп, көтүче сыман, болытларны куа да.
Янына барып җиткәнче, күпер инде югала.
Кушымта:

Еракта калган малай чак - бары тик хыял гына.
Хыял - салават күпере туа да юкка чыга.
Кушымта:

Салават күпере чыккан, кил, барып карыйк тагын!
Хәтернең ал офыгына йөгерә бала чагым…